ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 644-219/кс-2022

2023 елга «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыятенең «Казаньнефтепродукт» филиалы өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыятенең «Казаньнефтепродукт» филиалы тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыятенең «Казаньнефтепродукт» филиалына иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы

җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022 елга «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыятенең «Казаньнефтепродукт» филиалы өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү хакында» 16.12.2021 №678-201/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 644-219/кс-2022
карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Татнефтепродукт» ХК акционерлык җәмгыятенең «Казаньнефтепродукт» филиалы тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасында җиткерелә торган кайнар суга 2023 елга тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (бер компонентлы), сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәре белән | | | | кайнар су белән тәэмин итүнең тышкы челтәреннән башка | | | |
| | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | | изоляцияләнгән торбалар белән | | изоляцияләнмәгән торбалар белән | |
| | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | | сөлге киптергечләр | |
| | | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк | әйе | юк |
| | Казан шәһәре | | | | | | | | |
| 1 | «Татнефтепродукт» ХК АҖ «Казаннефтепродукт» филиалы | | | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 156,58 | 146,28 | 167,09 | 156,58 | 151,43 | 141,12 | 161,94 | 151,43 |
| 1.2 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 130,48 | 121,90 | 139,24 | 130,48 | 126,19 | 117,60 | 134,95 | 126,19 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге